ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                    КАРАР

_______________          с. Верхний Услон          _______________

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы чикләрендә җирлекләр арасында автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында " 2016 елның 16 ноябрендәге 1096 номерлы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 480-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2018 елның 11 апрелендәге 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Нигезләмәнең 5 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 5.2.2 пункт өстәргә:

   «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут картасы ачык конкурс үткәрмичә генә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән очракта бирелә:

   гадәттән тыш хәл шартларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү максатларында билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча».

Нигезләмәнең 5 бүлегенең 5.6 п.«2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы һәм 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен өстәргә.

3. Нигезләмәнең 5 бүлегенең 5.7 п. төшереп калдырырга
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитетының җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды
О.А.Сельская